СОВЕТ КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

РЕШЕНИЕ                                                  КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-

27.08.2025                    д. Канаш                    №47-261

Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәнең үз көчен югалтуын тану турында.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, "Коррупциягә каршы көрәш турында" 25.12.2008, №273-ФЗ номерлы Федераль законнар, "Муниципаль вазыйфаны яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе турында" 19.07.2017 ел N 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Советының 24.10.2019 ел № 61-281 карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне үз көчен югалткан дип танырга (15.06.2021 ел № 09-56, 20.06.2022 ел №17-99, 07.03.2023 ел №25-143 үзгәрешләр белән).
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы                                    Н.Н.Вальков